| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ЛЕНИНОГОРСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>«ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

20.05.2021 г.Лениногорск № 32

Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советы карарын гамәлдән чыгару турында

Гамәлдәге закон нормаларына туры китерү максатыннан, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Лениногорск муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советы карарын гамәлдән чыгарырга:

«Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә җирләрне махсус сакланыла торган җирле әһәмияттәге җирләргә кертү тәртибе турында» Нигезләмә турында» 2010 елның 17 декабрендәге 32 номерлы карары;

«Лениногорск муниципаль районында гражданнарны аз керемлеләр дип тану һәм аларга муниципаль торак фондыннан социаль наем килешүләре буенча торак урыннары бирү максатларында гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнәр күләмен һәм алар милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакын билгеләү тәртибе турында» 2013 елның 26 апрелендәге 25 номерлы карары;

«Социаль наем һәм дәүләт торак программалары буенча гражданнарга торак биргәндә һәм торакны исәпкә куйганда торак мәйданы нормалары турында» 2014 елның 24 декабрендәге 106 номерлы карары.

2. Әлеге карарны рәсми публикатор-«Лениногорские вести» газетасында бастырырга һәм Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninoqorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Лениногорск
муниципаль районы Башлыгы,
Совет рәисе

Р.Г.Хөсәенов